СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

8 ФЕВРАЛЬ, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. № 15 (8027) Бәясе билгеләнгәнчә.

## ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘЛӘРДӘН АКТИВЛЫК СОРАЛА

### (Район хакимиятендә киңәшмә)

5 февральдә район хакимиятендә узган зур киңәшмәдә каралган мәсьәләләрнең иң әһәмиятлесе райондагы җирле үзидарә Советларының «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законында каралган функцияләрен һәм бурычларын практик гамәлгә ашырырулары мәсьәләсе булды. Киңәшмәне ачып, халык депутатларының район Советы рәисе, хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллин, әгәр сиңа җитәкчелек итү ышанып тапшырылган икән, вазифаларыңны ничек башкаруың турында хисап тотарга әзер булу да кирәк, дип, мондый эшче очрашуларның быел традицион төс алачагын әйтте.

Хакимият аппараты, район Советы хезмәткәрләре, җирле үзидарә Советлары рәисләреннән тыш районның төрле службалары җитәкчеләре һәм район эчке эшләр бүлегенең участок инспекторлары да катнашкан, төпле һәм җитди, урыны белән бик кискен тонда да сөйләшүгә корылган бу киңәшмәне Ф.С.Сибагатуллин Октябрь районы прокуроры итеп куелган Александр Петрович Евграфов белән таныштырудан башлады. Аксубай районында туган А.П.Евграфов соңгы вакытта Яр Чаллы шәһәре тикшерү органнарында эшләгән. Аның профессиональлеген билгеләп үтеп, Фатыйх Сәүбәнович хокук саклау органнары җинаятьчелеккә һәм хокук бозуларга каршы көрәш буенча алар алдына куелган бурычларны кыюрак хәл итсеннәр иде дигән теләк белдерде. Фатыйх Сәүбәнович 1996 елда шәһәрдә һәм районда беләторып үтерүләр саны, гәрчә алар ачылса да, артуына җитди борчылуын әйтте һәм шул контекстта участок инспекторларына һәм Советлар җитәкчеләренә урыннарда профилактика эшен көчәйтергә чакырып мөрәҗәгать итте.

Район Советы рәисенең чыгышы ары таба төгәл программ характерда барды. Советларның мәшәкатьләре мең төрле, әмма авыл кешесенең керемененң төп чыганагы булган җир, аның уңдырышлыгын күтәрү турында кайгырту - шуларның беренче чираттагыларыннан. Җиргә яңадан хуҗа булдырырга кирәк - моның зарурлыгы бүген көн кебек ачык. Фатыйх Сәүбәнович бу уңайдан бер мисал китереп үтте. «Москва» крестьян хуҗалыклары ассоциациясе базасында авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү буенча өч күмәк берләшмә оешты. Ассоциация членнарының җир пайлары да ачыклана. Әйе, бүген реформасыз һич мөмкин түгел, аларын базар мөнәсәбәтләре китереп чыгара. Советлар бу мәсьәләдә урыннардагы хәлне анык белеп торырга, җирдән файдалану өчен җавап та бирергә тиешләр. Авылдагы гаиләләрнең керемен арттыру өчен, диде Ф.С.Сибагатуллин, йорт яны участокларын киңәйтергә, аларда бәрәңге, башка культуралар үстерергә, терлек симертеп сатарга кирәк. Авыл халкына бу эштә бар яклап булышу - Советларның беренчел бурычы. Авылларны социаль үстерүне тәэмин итү буенча бурычлардан Фатыйх Сәүбәнович торак пунктларны төзекләндерү һәм газлаштыру мәсьәләләрен хәл итүне, халыкка көнкүреш, сәүдә һәм медицина хезмәте күрсәтүне яхшыртуны, мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениеләре һәм мәктәпләр, физик тәрбия һәм спорт, җәмәгать тәртибен саклау һәм башка проблемаларны атап үтте. Җирле үзидарә Советлары боларның барчасын хәл итү буенча да армый - талмый эшләргә тиешләр.

( Ахыры 2 нче биттә).

## ИРТӘГӘ - УРАЗА ГАЕТЕ

**Иртәгә Ислам диненең иң зур бәйрәмнәреннән берсе - Рамазан ае тәмамлангач билгеләп үтелә торган Ураза бәйрәме башлана. Бу бәйрәм шәүвәл аеның, ягъни Ай елы исәбенең 10 нчы аеның беренче көненә туры килә һәм Рамазан бәйрәме, Фитыр бәйрәме, Гает бәйрәме дип төрле исемнәр белән аталып йөртелә.**

Дөньяда бәйрәмнәр күп, һәр халыкның, җәмгыятьнең үз бәйрәмнәре бар. Әмма бу бәйрәм башка, бер миллиардтан күбрәк мөселманның 70 тән артык илдә үткәрә торган иң бөек бәйрәме.

Мөселманнар Аллаһ ризалыгы өчен бер ай буе ач тордылар, уразаларын тәмамладылар, Аллаһ тәгаләдән ярлыкау ялвардылар, тәүбә иттеләр, догалар укыдылар. Бу тырышлыклар бушка китмәс: бөтен мөселманнар Аллаһның ярлыкавына ирешәчәк, йөзләр көләчәк, күңелләр нур белән тулачак, өйләр яктырып калачак.

Бәйрәм көннәрендә бөтен җирдә туганлык хисе хөкем сөрә. Бер - берсенә үпкәләгән кешеләр килешергә, дуслар очрашырга тиеш. Туганнар бер - берсен йөреп чыгарга, әти - әнисенең кулларын үбәргә, хәл - әхвәл сорарга, балалар атасының дусларына барып килергә тиеш. Бер - берсенә үпкәләгән кешеләр, үзләре генә килешә алмасалар, аларны төрле юллар белән дуслаштырырга кирәк.

Бу көнне балалар иң матур күлмәкләрен киярга тиеш. Ятимнәр, фәкыйрьләр, бәхетсезлеккә очраган кешеләр дә игътибардан читтә калмасын. Бер үксез ятимнең аягыннан тартып алган шырпыны да раббымыз иң матур чәчәккә әйләндерәчәк, бу яхшылыкны эшләгән кешене кабер тормышында бәхетле итәчәк.

Шуны онытмагыз, ятим балага бүләк иткән аяк киеме, бәлки, Кыямәт көнендә сезнең каршыгызга яклаучыгыз булып килеп басар. Гомумән, сез күрсәткән ярдәм һәм изгелек, хәер - садакалар бер вакытта да эзсез калмаячак!

Бәйрәм көнне бик иртә торырга, юынырга һәм чиста өс - башы киенергә кирәк. Мәчеткә киткәндә ашыгырга ярамый. Юлда мәһабәт адымнар белән, Аллаһны уйлап, аны тәкъбир әйтеп барырга кирәк. Бәйрәм намазына җыйнаулашып - картлар, яшьләр, бала - чагалар бергәләшеп барсалар бик яхшы була. Бәйрәм мөнәсәбәте белән беренче тапкыр намазга килгәннәргә көлеп карарга ярамый. Киресенчә, аларны шәфкать һәм якты йөз белән сәламләргә, бәйрәм белән тәбрикләргә, хәл - әхвәлләрен сорашырга кирәк. Намаздан соң бәйрәм рухы йорт эчләренә күчә, тәбрикләүләр, котлаулар башлана.

**Гает намазы 9 нчы февраль көнне иртәнге сәгать 8дә укылачак.**

### Игътибар: концерт булмый

Районда грипп һәм башка распиратор инфекция эпидемиясе хөкем сөргәнлектән, җырчы Разия Гайнуллина иҗатына багышлап 9 февральдә үткәреләсе зур концерт булмаячак.

## БОРЧУ - МӘШӘКАТЬНЕҢ БЕТКӘНЕ ЮК

**Районның эпидемиягә каршы санитар комиссиясендә**

### САК БУЛЫГЫЗ: ГРИПП!

Күптән түгел эпидемиягә каршы санитар район комиссиясенең чираттагы утырышында районда гриппны кисәтү һәм аны нәтиҗәле дәвалауны оештыру чаралары турында җитди сөйләшү булды. Бу йогышлы авыру бездә дә хакимлек итә. Карарда билгеләп үтелгәнчә, 1997 ел башыннан районда грипп һәм башка кискен распиратор инфекцияләр белән авыручылар саны арткан. Гыйнвар аенда гына да 249 кеше грипп, 461 кеше ОРВИ белән авырган. Гомуми авыручыларның 55,9 процентын балалар тәшкил итә. Шәһәрнең 3 нче, Яңа Әмзә, Бикүле мәктәпләрендә укучыларның 15 - 27 проценты авырыйлар.

Югарыда күрсәтелгәннәргә нигезләнеп, комиссия кабул иткән карарда гриппка каршы һәм аны дәвалау буенча чаралардан тыш, эпидемиологик куркыныч чорында культура учакларында, мәктәпләрдә үткәрелә торган массакүләм мәдәни, спорт чаралары, ярышлар, культпоходларны чикләү турында да пункт бар.

АВЫРЫЙ БЫЗ!

*Басылганга кире кайтып*

### «ТУҢАБЫЗ !!!»

Бер атна элек хуҗалыкара төзелеш оешмасы котельнясыннан җылытыла торган тулы бер микрорайонның җылысыз калуы турында язган идек. Кызганычка каршы, йортларга һаман да җылы бирелмәве турында зар белән төрле инстанцияләргә мөрәҗәгать итүчеләрнең беткәне юк әле, андый зар белән безгә дә киләләр.

Шул уңайдан кичә район хакимияте каршында гадәттән тыш хәлләр буенча комиссия рәисе, хакимият башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев һәм МСОның баш инженеры Р.М.Карама белән телефон аша элемтәгә кердек. Сөйләшүләрдән аңлашылганча, күпкатлы йортларга җылы бирелде инде, бары Циалковский урамындагы 105 фатирлы 11 нче йортның тагын өч подъезды гына калып бара.

Ә менә шәхси секторда, шул исәптән МСОның һәм башка оешмаларның усадьба тибындагы йортларыннан торган урамнарда хәл катлаулы әле. Аларның һәрберсенә җылы бирү өчен МСОның үз көчләре генә җитмәячәген искә алып, хакимият башлыгы ул эшне 10 предприятие һәм оешмага бүлеп бирү турында карар чыгарды. Шикәр заводы, НГДУ, НУРБ, «Татагропроммехмонтаж» ПМКсы, машина төзү заводы үзләренә билгеләнгән урыннарда эшкә шундук тотындылар. Башкалар да халыкны бу бәладән коткаруга җитди карарлар дип ышанабыз.

Шул ук вакытта йорт һәм фатир хуҗаларыннан да аларга куллан килгән ярдәмне күрсәтүләре һәм җылылык трассасын сафка бастыру таләпләрен төгәл үтәүләре сорала.

### СПОРТКОМПЛЕКСНЫ УТ АЛДЫ



ЯНАБЫЗ!

Ут төсле үгез елы Норлат шәһәренә беренче көннәрендә үк дәһшәтле янгыннарын алып килгән иде. Инде менә 6 нчы февраль иртәсендә «Норлатнефть» НГДУсының спорткомплексында чыккан зур янгын шәһәрне тагын бер кат тетрәтте. Вакытында килгән берничә янгын сүндерү командасы үз эшен белеп башкаруга карамастан, көчле ут үзенекен итте: күпме бала - чага, яшьләр һәм олыларның физик мавыгуы өчен җайлы булган һәм никадәр зур матди байлык саналган комплекс күз алдында юкка чыкты. Бу чыгымнарның саннарда ничегрәк янгыравын һәм янгын чыгуның сәбәпләрен тиешле органнар тарафыннан ачыкланганнан соң ишетербез.

**Фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ бу рәсемне янгын пыскып ятканда төшереп алган.**

РЕСПУБЛИКАБЫЗДА

### БЕР УРЫНГА - ӨЧ КАНДИДАТ

Рәис Кыям улы Беляев үлгәннән соң Татарстан Республикасы Дәүләт Советында 103 нче сайлау округы буенча депутат посты бушады. Март аенда Тукай районында кабат сайлаулар булачак. Татар иҗтимагый үзәгенең Чаллы бүлеге депутатлыкка кандидат итеп исеме яхшы таныш эшмәкәр, ТИҮ лидерларының берсе Рәфис Кашаповны күрсәтте. Икенче кандидат «Иттифак» партиясенең рәисе, шулай ук исеме яхшы таныш язучы Фәүзия Бәйрәмова. Улүзе өчен март сайлауларын зур сәясәткә әйләнеп кайтуда соңгы шанс дип саный. Бөтентатар милли мәҗлесенең элекке рәисе, хәзер «Ак барс» банкы җитәкчесе Тәлгать Абдуллинның да сайлауларда җиңүдә шансы зур.

Тумышы белән ул - Әлмәт районы Шарлама авылыннан. Бирелә, «Фрунзе» колхозында аның әтисе Нурми ага 35 ел рәислек итә. Биш бала арасында ул - икенчесе, ә хәзер инде туган энесе һәм ике сеңлесе өчен генә түгел, үзләре белән бер түбә астында үскән туганнан туган сеңелләре өчен дә иң өлкәне. Соңгылары - Нурми аганың яшьли тол калып аларга сыенган сеңлесенең ике кызы. Алар бер гаилә булып озак яшиләр. Балалар ата - ана җылысын һәм назын бәяләргә иртә өйрәнәләр: 4 нче класстан белем эстәргә күрше Яңа Михайловкага, 8 еллык мәктәпкә йөрергә туры килә, аннан урта мәктәпкә Түбән Мактамага йөреп укыйлар. Кышларын чаңгы булышса, җәй көннәрендә аларга велосипед ярдәмгә кирә.

... Шарлама. Ныклы йолалы, гадәттәгечә ачык күңелле, кунакчыл чын татар авылы - аның туган җире, яшел бишеге, яшәвенең чишмә башы була.

Шуннан соңгы тормыш баскычларына күз салыйк. 70 нче елда авыл хуҗалыгы институтының механика факультетын тәмамлый, юллама буенча «Төрнәс» совхозына килә. Әмма озаклап стажировка үтәргә туры килми, яшь белгечне ВЛКСМ райкомына икенче секретарь итеп алалар. Тагы ике елдан автотранспорт предприятиесе директоры итеп күчерәләр. Бу аның өчен зур практик эш мәктәбе була. Производство күрсәткечләре түбән, автопарк иске, шоферлар еш алышына, хезмәт хакы аз. Моннан чыгу юлы да булмас сыман. Әмма карар кәтмәгәндә тиз килә. Шикәр заводы белән буласы кагат кырларыннан җир ташырга килешү төзеп, шоферларны кич, төнлә эшләргә инандырып, алынган эш күләмен үтиләр. Шулай итеп, план күрсәткечләрен үтәүдә кинәт алга китешкә ирешәләр, бу исә табыш, акча дигән сүз. Ә иң мөһиме - кешеләр кәефе күтәрелү, уянган өметләр. Ул чакта АТП республиканың төрдәш предприятиеләре арасында беренче урынны ала һәм РСФСР автотранспорт Министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Коллективка Норлат шәһәре хезмәт ияләренең 1 нче Май демонстрациясен җитәкләү хокукы бирелә. Хуҗалык исәбе буенча торак, административ бина төзү мөмкинлеге дә туа...

# *ТУГЪРЫЛЫК*

*Шәхси календарьдагы дата*

***Гаилә, дуслар, эш. Бу өч магик төшенчәне ничек кенә урыннарын алыштырып санасаң да, нәтиҗәсе бер үк: өч бу сүзгә кешенең бөтен тормышы, язмышы сыеп бетә. Шул чылбырның берсе генә булмаганда да ул язмыш ничектер тулы килеп чыкмый. Безнең гади җир бәхетебезнең өч төп шарты, өч буыны, өч терәге әнә шулар. Тугърылык саклаганда, әлеге төшенчәләр һичшиксез язмышның бәхетле бүләге булып кодрәт һәм көч - куәт алалар.***

***Бу, билгеле, ачыш түгел. Бу - тормыштагы гаҗәеп һәм якты законлылыкка тагы бер дәлил генә. Бүгенге язмамның герое язмышында бу бөтенлек күпләрне кызыктырырлык һәм көнләштерерлек. Шуңа да коллегаларым белән гаҗәеп кешелекле һәм абруйлы җитәкче, кеше, гаилә башлыгы Әхмәтнәкыйп Нурмиевич Миназовны якты юбилее белән күпсанлы котлауларга кушылам.***



Тик... Кеше бер төрле ниятләсә, партия комитеты икенче төрле хәл итә. Нәкыйп Нурмиевичка да яңа әмер бирелә: «Төрнәс» совхозына китәргә. Холкы буенча юл куя торган булса да ул шактый озак тарткалаша. Соңыннан барыбер ризалаша, билгеле. Хатыны Сөембикә ул чакны елмаеп искә ала, улы туган шатлыктан Гыйматдиновка ризалык бирде, ди. Ә Төрнәс нәсел совхозында алты ел ярым җитәкчелек итү күпме кыенлыгы, эзләнүләре, өмет һәм ышанычлары, югалтулары һәм байтак елмайган шатлыклары белән исендә калды аның! Ул чакта хуҗалык сөрү җире буенча да, савым көтүе һәм дуңгызлар баш саны буенча да районда иң эреләрдән, ә территориясендә җитештерүнең төрлелеге ягыннан - районда бердәнбер иде. Шуңа да кешеләргә совхоз сферасыннан тыш та барып керергә урын җитәрлек була. Янә комсомолда эшләү тәҗрибәсе ярдәмгә алты ел ярым килде: ул кешеләргә ышанырга, алар фикере белән санашырга өйрәнгән иде. Үзара аңлашуга ирештеләр: кешеләр узгынчы җитәкче түгел, кайгыртучан, нык куллы хуҗа килгәнен күрделәр. Ә бит аңа ул чакта 30да юк иде әле! Бүген Нәкыйп Нурмиевич ул чакта иңгә - иң торып эшләргә туры килгән хезмәттәшләре - элеккеге урынбасары Зөфәр Харисович Сафин,сыер фермасы мөдире Антонина Никитична Жирнова, дуңгыз фермасы мөдире Василий Алексеевич Белов, механизаторлардан Петр Михайлович Казаков, Геннадий Дмитриевич Черевов, мастерскойлар мөдире - Михаил Иванович Синяков. Алар - көчле урта буын җитәкчеләре, сүзләре эштән аерылмый торган абруйлы кешеләр иделәр. Кешеләр мәнфәгатен берләштергән нәрсә булып янә киң җәелдерелгән хуҗалык объектлары, торак, социаль - культура - көнкүреш биналарын төзү булды Бер җыелыш аерата истә калган: клубны кайда төзергә? Ә махсус заказ буенча проектлаштырылган культура йортына иске клубтан ерак түгел авыл уртасында бик тә килешле урын булыр иде, әмма анда - бик матур каенлык. Кисәргә кызганыч. Шуңа да халык белән киңәшергә булдылар. Гөр килеп фикер алышканнан соң хәл иттеләр: кайда яхшы - шунда төзергә, ә агачларны яңадан да утыртырга була. Чыннан да, хәзер Төрнәснең мәдәни - мемориаль комплексы сугышта һәлак булган якташларына куелган һәйкәл янәшәсендә яшел каеннар һәм зәңгәр чыршыларга күмелгән, авылның бизәге булып утыра.

- Язмыш безгә бик мәрхәмәтле булды: тормышта да, хезмәттә дә әйбәт кешеләр белән очраштырды,- ди Нәкыйп Нурмиевич. - Зирәк, акыллы җитәкче Г.К.Гыйматдинов кебек кешенең ышанычын яулавым белән горурланам, мәрхүм Н.Л.Филиппов белән һәрчак уртак тел таба идек. Беренче комсомол туйларын без «Игенче» колхозы рәисе С.С.Гафуров белән, армиядән кайткан солдатлар белән очрашуларны - Ш.С.Хафизов белән оештырдык. Аларның һәрберсе без яшьләргә үзенең күңел җылысын сала белде. Гаиләмдә дә мин бәхетле, биредә мин ышанычлы тыл, тулы аңлау таптым. Дусларымнан да уңдым, чөнки 30 елга сузылган дуслык җепләребез нык, эчкерсез, ул инде хәзер безнең балаларыбыз дуслыгы булып үсте. Эшкә мөнәсәбәткә килгәндә, «бәхет» сүзе биредә бик тә туры килә. Аннан рухи канәгатьлек алу турында да әйтү кирәктер.

Н.Н.Миназовны якыннан белгән һәркем моны раслый ала. Кешеләрнең аңа җитәкче һәм шәхес буларак ихтирамы да шуны дәлилли. Зур, мәшәкатьле хуҗалык - Н.Октябрь элеваторын җитәкли ул. Соңгы ике елда биредә 100ләп кеше бушлай үзенең торак шартларын яхшыртты, хәзер ведомстволы күп фатирлы йортларны бушлай газлаштыру эшләре бара, эш урыннарында көнкүреш шартлары күзгә күренеп яхшыра, эзлекле рәвештә производство объектлары һәм куәтләрен яңарту программасы гамәлгә ашырыла.

... Үзенә һәм кешеләргә тугърылык саклаган кеше турында чын хикәят менә шундый. Озак һәм шатлыклы яшәгез, Нәкыйп Нурмиевич!

**Д.ТӘМАЕВА.**

# ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘЛӘРДӘН АКТИВЛЫК СОРАЛА

**( Ахыры . Башы 1 нче биттә).**

Безне салым турындагы законнарны үтәүнең торышы да җитди борчый, диде Ф.С.Сибагатуллин. Бу өлкәдә элеккечә үк финанс контроле йомшак әле. Исерткечле эчемлекләр белән сату итүгә лицензиясе булган предприятиеләрнең саны якын арада кыскарачагын һәм аларның кайберләре реаль керемнәрен яшереп калу белән шөгыльләнүен әйтеп, Фатыйх Сәүбәнович бу җәһәттән кулланучылар хокукларын саклау комитетының (Р.Г.Суфиянов) эшенә тәнкыйть күзлегеннән чыгып бәя бирде, бу өлкәдәге закон бозуларны юк итү буенча нәтиҗәле чаралар күреләчәген ассызыклады. Салымнарны тулысынча түләп бетермәүчеләрдән иң элек «Татнефтепром»ның Зүзәй нефть промыселы (В.А.Николаев) телгә алынды. Предприятиенең район бюджетына бурычы шактый. Гади хезмәт кешеләренең мөһим социаль ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә тотылырга тиешле акчалар менә кайда бит ул. Шул ук вакытта предприятие җитәкчелеге район үзәгендә зиннәтле аерым йорт төзелешен юмарт финанслый. Район Советы депутаты мандатына да ия була торып районны шул кадәр үк таларга ярамый бит инде, диде бу уңайдан Фатыйх Сәүбәнович.

Шулай да, гомумән алганда районда гомуми икътисадый хәл яхшыруга бара. Пенсияләр, бюджет учреждениеләрендәге хезмәткәрләргә эш хакы вакытында бирелә башлады. Район хуҗалыкларында кыр һәм фермаларның продукт бирүчәнлеген күтәрүгә юнәлтелгән максатчан эш алып барыла. Быел гыйнварда сөт сату 29 процентка артты, ит җитештерү үсә. Нефть чыгаручылар, тимер юлчылар, төзүчеләр һәм машина төзүчеләр кыенлыкларга карамастан үзләренең җитештерү программаларын әйбәт кенә үтәп киләләр. Һәркем үз эш урынында кызыксыну белән хезмәт итәргә тиеш - шул чакта нәтиҗә дә артачак.

Киңәшмә программасына тагын берничә мәсьәлә кертелгән иде. Район Советы рәисе урынбасары Е.К.Савинов халыктан сөт, ит һәм йон сатып алуны оештыру эшенә җентекле анализ ясады. Әлегә бу өлкәдә эш һич тә канәгатьләнерлек түгел, 1989 ел белән чагыштырганда хәзерләүләр күләме кискен кимеде. Күпчелек Советлар, шул исәптән Андреевка, Богдашкино, Урта Камышлы, Аксумла һәм башкалар бу эштән читләшеп аны үзагымына куйдылар. Авыл хуҗалыгы продукциясе тапшыручылар белән килешүләр төзелми, хуҗалыкларда үстерелгән терлекне Самара өлкәсеннән килеп җыеп китәләр, кайбер урыннарда хәзерләүчеләр бөтенләй юк, Коопзаготпром җыелган йон өчен дә халыкка вакытында түләми. Урыннарда Советлар эшенә контроль начар. Бу уңайдан Ф.С.Сибагатуллин Е.К.Савинов адресына тәнкыйть ясады, Коопзаготпром директоры З.З.Әхмәдиев һәм югарыда телгә алынган кайбер җирле үзидарә Советлары җитәкчеләренең аңлатмаларын тыңлады һәм килеп туган хәлне яхшырту буенча конкрет тәкъдимнәр кертте. Халыктан авыл хуҗалыгы продуктлары сатып алуны оештыру һәр Советның аерым игътибар үзәгендә булырга тиеш. Терлекне Норлат ит комбинатына тапшырырга кирәк, ә тегесе үз чиратында 3 - 7 көн эчендә исәп - хисап ясарга тиеш. Сөт һәм ит тапшыручыларга ассоциацияләрдән терлек азыгы, яшь терлек бирелү дә гарантияләнгән булу шарт.

- Халык турында кайгыртасың икән, аның нәтиҗәсе дә күз алдында булачак, диде Ф.С.Сибагатуллин.

Аннан соң киңәшмәдә район прокуроры А.П.Евграфов чыгыш ясады. Ул 1991 нче елдан җинаятьчелекнең 35 процентка артканлыгын билгеләп үтте. Авыр җинаятьләр саны күбәйде. Балигъ булмаганнар арасында наркомания белән шөгыльләнү очраклары икеләтә артты. Моның сәбәпләренең берсе итеп оратор урыннарда профилактика эшенең дәрәҗәсе түбән булуны әйтте. Җирле үзидарә Советлары халык арасында эчүчелек һәм алкоголизмга каршы көрәштән асылда читләштеләр. Авыл җирендә тәүлекнең теләсә кайсы вакытында «шешә» табып була. Шул ук вакытта 1996 елда аракы белән законсыз (рөхсәтсез) төстә сату иткән өчен фәкать 15 кеше җавапка тартылган. Иптәшләр судлары, эчүчелеккә каршы көрәш буенча административ комиссияләр һәм башка җәмәгать берләшмәләре таралган. Бу эш практикасына яңадан әйләнеп кайтырга кирәк.

Район хакимияте башлыгы урынбасары - финанс бүлеге мөдире Р.Г.Билалов 1997 елга район бюджетын формалаштыру эше тәмамлануы һәм аның халык депутатларының район Советы сессиясе каравына куелуы турында әйтте. Былтыргы бюджетның үтәлешенә кагылып Р.Г.Билалов бу эштә җитди кыенлыклар булганлыгын билгеләп үтте. Җирле үзидарә Советлары җитәкчеләренең игътибарын халыктан салымнарны тулы күләмдә җыю кирәклегенә юнәлтеп, ул үз чыгышында дәүләт средстволарыннан рациональ һәм экономияле файдалану буенча таләпләрнең катгый булуын ассызыклады.

Киңәшмәдә башка агымдагы мәсьәләләр дә каралды.

# Татарстан Республикасы халык депутатын сайлау буенча участок сайлау комиссияләрен оештыру турында

**халык депутатларының Октябрь район Советы президиумы карары**

**(Дәвамы. Башы 14 нче санда).**

**527 нче Якушкино сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Олег Николаевич **ЛАРИОНОВ**, «Заря» КХА хуҗалык мөдире.

**Комиссия членнары:** Игорь Исаевич **Ермилов** - «Заря» КХА шоферы, Жозефина Ивановна **Иштуллина** - «Заря» КХА ветеринария техникы, Светлана Алексеевна **Николаева** - Якушкино җирле үзидарә Советы кассир - бухгалтеры, Александр Исаевич **Перепелкин** - «Заря» КХА газовигы, Юрий Кузьмич **Столяров** - Якушкино урта мәктәбе укытучысы, Светлана Валерьевна **Толчина** - Якушкино фельдшер - акушерлык пункты акушеркасы, Вячеслав Леонидович **Шкаликов** - Якушкино урта мәктәбенең физик тәрбия җитәкчесе, Людмила Александровна **Яковлева** - Якушкино авыл китапханәчесе.

**528 нче Абрыскино сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Семен Данилович **ЯКОВЛЕВ**, «Родина» КХА мастер - көйләүчесе.

**Комиссия членнары:** Петр Тимофеевич **Андреев** - Якушкино урта мәктәбе укытучысы, Светлана Георгиевна **Архипова** - Якушкино урта мәктәбе укытучысы, Юлия Петровна **Кольцова** - «Родина» КХА ветеринария табибы, Маргарита Леонидовна **Питуганова** - Абрыскино фельдшерлык пункты санитаркасы, Юрий Семенович **Сандрюхин** - «Родина» КХА терлекчесе, Валентина Николаевна **Сандрюхина** - Абрыскино башлангыч мәктәбе мөдире.

**529 нчы Салдакай сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Рунар Рәфыйк улы **ГАЛИУЛЛИН**, Салдакай урта мәктәбе укытучысы.

**Комиссия членнары:** Олег Тихонович **Васильев** - «Родина» КХА тракторчысы, Петр Иванович **Илюхин** - «Родина» КХА экономисты, Марина Николаевна **Кузнецова** - Салдакай авылы китапханәчесе, Гөлсирә Кыям кызы **Логинова** - Салдакай урта мәктәбе укытучысы, Светлана Александровна **Павлова** - Салдакай урта мәктәбе укытучысы, Гомәр Минсабир улы **Йосыпов** - «Родина» КХА терлекчесе.

**530 нчы Бикүле сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Зөфәр Сабирҗан улы **МИННЕГОЛОВ**, Бикүле урта мәктәбе укытучысы.

**Комиссия членнары:** Бибинур Гәрәй кызы **Әбделвәлиева** - Бикүле авылы мәдәният йорты директоры, Гөлия Гыйнияз кызы **Камалова** - Бикүле урта мәктәбе укытучысы, Гөлүсә Гәрәй кызы **Садыйкова** - Муса Җәлил исемендәге КХА экономисты, Роза Госман кызы **Хамматова** - Бикүле җирле үзидарә Советы хәрби учет өстәле начальнигы, Гөлсинә Вәгыйзь кызы **Шәйхетдинова** - М.Җәлил исемендәге КХА бухгалтеры ярдәмчесе, Исмәгыйль Әхмәт улы **Шәкүров** - Бикүле урта мәктәбе укытучысы.

**531 нче Кәкре Атау сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Вахит Касыйм улы **ЗӘЙНЕТДИНОВ**, Кәкре Атау урта мәктәбе директоры.

**Комиссия членнары:** Рәшит Усман улы **Гомәров** - «Чирмешән» КХА шоферы, Фидания Сәлимгәрәй кызы **Кәримова** - «Чирмешән» КХА бухгалтеры, Гөлкәй Усман кызы **Сибгатуллина** - Кәкре Атау урта мәктәбе укытучысы, Рифкат Ислам улы **Сиражетдинов** - «Чирмешән» КХА хуҗалык мөдире, Мөнир Сәмигулла улы **Хәлиуллин** - «Чирмешән» КХА ясалма орлыкландыручысы, Гүзәлия Наил кызы **Яхина** - «Чирмешән» КХА бухгалтер - кассиры.

**532 нче Илюткино сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Галина Васильевна **ГЕРАСИМОВА**, Илюткино урта мәктәбе директоры.

**Комиссия членнары** - Зинаида Ивановна **Антонова** - «Москва» КХА сөт җыючысы, Антонина Петровна **Абрамова** - Илюткино авылы китапханәчесе, Алексей Павлович **Воронцов** - «Москва» КХА хуҗалык мөдире, Надежда Владимировна **Казакова** - авыл мәдәнияt йорты директоры, Ваталий Леонтьевич **Михайлов** - Илюткино урта мәктәбе укыту бүлеге мөдире, Ольга Геннадьевна **Сергеева** - Илюткино урта мәктәбе укытучысы.

**533 нче Биляр Озеро сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Светлана Леонидовна **МИКУШКИНА** - Биляр Озеро урта мәктәбе директор урынбасары.

**Комиссия членнары:** Лариса Валериевна **Ерепова** - «Путь к коммунизму» КХА бухгалтеры, Анатолий Иванович **Ильдюшин** - Биляр Озеро урта мәктәбе укытучысы, Людмила Николаевна **Маркова** - Биляр Озеро мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе, Елена Анатольевна **Нагорнова** - Биляр Озеро авылы китапханәчесе, Маргарита Анатольевна **Савенко** - җирле үзидарә Советы секретаре, Валентина Анатольевна **Сычева** - Биляр Озеро мәдәният йорты директоры.

**534 нче Гәйтән сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Алевтина Александровна **ГРАФ** - Гәйтән урта мәктәбе директоры.

**Комиссия членнары:** Татьяна Витальевна **Акмуллина** - Гәйтән авылы китапханәчесе, Марина Ивановна **Григорьева** - Гәйтән урта мәктәбе лаборанты, Тамара Анатольевна **Кузьмина**, Валентина Владимировна **Родионова** - Гәйтән урта мәктәбе укытучылары, Алексей Александрович **Пайгерчев** - «Виктория» КХА шоферы, Марина Васильевна **Панина** - Гәйтән урта мәктәбе укытучысы.

**535 нче Биккол сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Илфат Галимулла улы **ӘҺЛИУЛЛИН**, Биккол урта мәктәбе директоры.

**Комиссия членнары:** Вахит Шәрифҗан улы **Вильданов** - Биккол урта мәктәбе укытучысы, Зөлфия Рәшит кызы **Закирова** - Биккол урта мәктәбе өлкән вожатые, Рузилә Вәзир кызы **Мөхәммәдиева**, Роза Сәлим кызы **Салахова** - Биккол урта мәктәбе укытучылары, Раилә Тәлгать кызы **Хатыйпова** - «Таң» КХА бухгалтеры, Ринат Тәлгать улы **Шаһиев** - Биккол урта мәктәбе укытучысы.

**536 нчы Фома сайлау участогы**

**Комиссия рәисе** - Ханифә Әхәт кызы **ШӘФИГУЛЛИНА**, Фома авылы китапханәчесе.

**Комиссия членнары:** Фәридә Галимулла кызы **Абдрахманова** - «Игенче» КХА кассиры, Руфия Хәлим кызы **Гомәрова** - Фома җирле үзидарә Советы баш бухгалтеры, Рамилә Хәмзә кызы **Кәримова** - «Игенче» КХА бухгалтеры, Фәридә Дамир кызы **Мәхмүтова** - балалар бакчасы мөдире, Затия Сәмигулла кызы **Мингалимова** - комплекслы кабул итү пункты кабул итүчесе, Әлфия Хөснулла кызы **Ситдыйкова** - «Игенче» КХА чөгендерчесе.

**(Дәвамы бар).**

# *«Без зур социаль әһәмиятле проблеманы хәл итәбез»*

Югары мәктәп

***Көнчыгыш икътисад, гуманитар фәннәр, идарә һәм хокук институтының (ВЭГУ) Бөгелмәдәге вәкиллеге җитәкчесе, техник фәннәр кандидаты РӘВИС СӘГЪДӘТ улы ШӘРИФУЛЛИН сөйли:***

Дәүләт бүген халык мәгарифе һәм яшьләрнең мәшгульлеге пролемасын үзе генә тулысынча хәл итә алмый: укырга теләгән барлык кешене дә ВУЗларга һәм махсус урта уку йортларына кабул итү өчен миллиардларча сум акча кирәк, ә дәүләтнең ул кадәр средствосы юк һәм булыр төсле дә күренми.

Шуңа күрә дә мондый шартларда югары белем бирүнең бюджеттан тыш формаларын булдыру идеясе туды һәм дәүләттән бер тиен дә акча алмыйча белем бирү системасы формалашты. Хәзер шундый уку йортларында дистә меңнәрчә яшь кеше белем ала.

1993 елның гыйнварендa Уфада оештырылган безнең институт та - шундый уку йортларының берсе. Институтның РФ Югары белем буенча дәүләт комитеты тарафыннан бирелгән һәм «юриспруденция», «икътисад», «педагогика» юнәлешләре буенча югары профессиональ белем бирү эшчәнлеге белән шөгыльләнергә рөхсәт итә торган лицензиясе бар. Былтыр Россия уку йортларын аттестацияләү буенча Дәүләт инспекциясе үткәргән экспертиза вакытында да эшебезгә югары билгеләр куелды.

ВЭГУ каршында Башкорт икътисадый - юридик колледжы, Гуманитар колледж, фәнни - тикшеренү институты, квалификация күтәрү һәм өстәмә белем бирү институты, Мәскәү дәүләт социаль университетының укыту - консультация пункты бар. Институтларда һәм колледжларда белем бирүдә 400ләп профессиональ укытучы, шул исәптән дәүләти вузлардан да белгечләр катнаша. Укытучыларбыз арасында 9 академик һәм әгъза - мөхбир, 48 фән докторы һәм профессор, 178 фән кандидаты һәм доцент бар.

Институтта фәнни - тикшеренү эшләренең дә колачы киң, бу юнәлештәге планнар үзебездәге һәм чит илләрдәге фәнни оешмалар белән уртак эшчәнлек алып баруга корылган. Спонсорлык һәм һимаячелек буенча да киң программалар гамәлгә ашырыла.

Институтның Уфада һәм башка шәһәрләрдәге матди базасы нык. Укыту процессы компьютерлаштырыла:8 уку классы заманча программалы иң яңа машиналар белән җиһазландырылган. Фәнни һәм мультимедияле китапханәләр фәннең төрле юнәлешләренә караган иң яңа басмалар һәм программалар белән тулыланып тора. Институтның заманча полиграфик җиһазлар урнаштырылган үз нәшрияты бар. Студентларыбыз укыту - методик әдәбиятның тулы комплекты белән бушлай тәэмин ителәләр.

Студентлар белән дәресләрдән тыш эшчәнлек программасы фән һәм мәгариф, хезмәткә урнаштыру һәм мәшгульлек, буш вакыт һәм культура, халыкара элемтәләр, туризм, спорт, мәгълүмат кебек юнәлешләрне үз эченә ала. Институтта музыка һәм театр студияләре, КВН клубы эшли.

ВЭГУда өч: юридик, икътисад һәм педагогика факультетлары бар. 1994 елдан бирле Бөгелмәдә институтның вәкиллеге эшләп килә. Шушы вакыт эчендә безгә 200дән артык кеше укырга керде.

Укырга кабул итү елына ике тапкыр - яз һәм көз үткәрелә, ягъни укулар да мартта һәм сентябрьдә башлана. Хәзер, ягъни гыйнвар - февральдә язгы кабул итү бара. Аның үзенчәлеге шунда, без бу юлы урта белемлеләрне генә түгелә, 11 нче класс, шулай ук техникум һәм училищеларның өченче курс укучыларын да кабул итәбез. Кабул итү имтиханнарсыз, әңгәмә һәм тест сорауларына бирелгән җаваплар нигезендә уздырыла. Аңлашылганча, бездә уку читтән торып һәм түләүле. Әмма түләү башка уку йортлары белән чагыштырганда чамасыз түгел. Укыган өчен түләүдә кайбер ташламалар да бар.

Уку срогы 5 ел. Югары яки бер профильле урта профессиональ белемгә ия булган, шулай ук уку программасын уңышлы үтәүче студентларга кыскартылган сроклы индивидуаль планнар буенча уку мөмкинле[illegible] дә бирелә.

Кабул итү комиссиясенә паспорт, белем турында документ (һәм аның күчермәсе) яки уку йортыннан билгеләр ведомосте белән бергә белешмә, 086 - У формалы медицина белешмәсе, 3 х 4 зурлыктагы өч фотоpәсем һәм 6 конверт тапшырыла.

Заманча һәм абруйлы белгечлекләр буенча укырга теләге булганнарны үзебездә көтәбез. Безнең адрес: 423200, Бөгелмә шәһәре, Я.Гашек урамы, 10, телефоннар: 5 - 39 - 45, 5 - 35 - 12. Белешмәләр өчен Норлатта телефон: 2 - 23 - 37.

***Бисмилләһир - рахман - иррахим***

## Кадер сүрәсенә ияреп

Коръән иңгән изге айдыр,
Изге айдыр Рамазан.
Башкаенны куй сәҗдәгә,
Изгелек кыл һәр заман.

Зур бәйрәм бар - Кадер киче
Бу гүзәл ай эчендә.
Гафел булма, кыл син дога
Рамазан ае эчендә.

Кадер киче доган кабул,
Мең ел гыйбадәт савабы
Фәрештәләр алып килер,
Аллаһының сәламен.

Рәхим - шәфкать, игелекнең
Әҗера күп бу айда.
Елга бер кич - ул кадер кич,
Укы дога, кыл файда.

**Тәзкирә АЛЯКИМОВА.**
**Түбән Норлат авылы.**


## Белдерүләр

## Сатабыз

**4 - 5 сантиметр калынлыктагы 5 - 6 метрлы нарат такта. 1 куб. метры 400 мең сум.** Тел.: 5 - 27 - 41, 5 - 11 - 44.

***

**ГАЗ - 52 - 53А, УАЗ - 3303 автомашиналары.** Чулпан авылында Солтан Хөснулловка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Әйбәт хәлдәге диван һәм кәнәфиләр.** Адрес: Октябрьская ур., 56 - 1, тел.: 2 - 21 - 07.

***

**Каралты - курасы белән йорт, мунчасы, коесы, җәйге кухнясы бар.** Мамык авылында Хөсәеновка мөрәҗәгать итәргә.

***

**7000 километр йөргән ВАЗ - 21065.** Тел.: 2 - 25 - 59 (эш).

***

**Компакт - дисклары белән яңа музыкаль үзәк (Япония).** Тел.: 2 - 18 - 81.

***

**Ипподромнан 4 яшьлек чабыш айгыры.** Аксубай районында тел.: (8-244) 4 - 13 - 12.

## Алмаштырабыз

**Ике бүлмәле фатирны - бер бүлмәлеләргә.** Адрес: Горький ур., 16.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның сишәмбе, җомга көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2071 данә. **Заказ № 5632.**